**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

## Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентын раслау турында» 2008 елның 4 апрелендәге ПУ-162 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2010 елның 7 октябрендәге ПУ-667 номерлы, 2013 елның 7 маендагы ПУ-385 номерлы, 2013 елның 23 ноябрендәге ПУ-1144 номерлы, 2014 елның 14 августындагы ПУ-788 номерлы, 2015 елның 22 маендагы ПУ-473 номерлы, 2016 елның 30 гыйнварындагы ПУ-67 номерлы һәм 2016 елның 25 июнендәге ПУ-550 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентына әлеге Указ нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләрен таныштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 ел, 12 август
№ ПУ-685

Татарстан Республикасы
Президентының
2016 елның «12 » августындагы
ПУ-685 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентын раслау турында» 2008 елның 4 апрелендәге ПУ-162 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентына кертелә торган үзгәрешләр**

1. 4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Татарстан Республикасы Президенты уздырган киңәшмәләрдә кабул ителгән карарлар беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

Чаралар (эш сәфәрләре, очрашулар, объектларда булу, визитлар һ.б.) уздыру барышында Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан бирелгән йөкләмәләр, Татарстан Республикасы Президентының телдән биргән йөкләмәләре йөкләмәләр исемлеге белән рәсмиләштерелә.

Беркетмә (йөкләмәләр исемлеге) проекты Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында эш башкару инструкциясе таләпләре нигезендә рәсмиләштерелә.».

2. 4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Киңәшмә беркетмәсе (йөкләмәләр исемлеге) проекты тиешле өлкәдә Татарстан Республикасы Президентының эшчәнлеген тәэмин итүче Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе яисә Аппаратның структур бүлекчәсе яисә киңәшмәне (чараны) уздыру инициаторы булган орган тарафыннан киңәшмә (чара) уздырылган көннән соң кимендә өч көн дәвамында һәм киңәшмә беркетмәсендәге яисә йөкләмәләр исемлегендәге йөкләмәләр һәм карарларны (алга таба – беркетмәдәге йөкләмәләр) үтәү вакыты җитүдән соңга калмыйча төзелә. Беркетмә (йөкләмәләр исемлеге) проекты киңәшмәләр (чаралар) вакытында яздырылган стенограмма һәм аудиоязманы расшифровкалау, бирелгән тезислар, докладлар һәм чыгышлар, белешмәләр, карарлар проектлары һәм башка чыганаклар нигезендә төзелә. Беркетмә (йөкләмәләр исемлеге) проектына мәҗбүри рәвештә түбәндәге нигезләмәләр кертелә:

беркетмәдәге йөкләмәләрне үтәүне контрольдә тотуны Татарстан Республикасы дәүләт органына йөкләү (әгәр йөкләмәләр берничә ведомствога караса, контрольдә тоту Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләнә);

беркетмәдәге йөкләмәләрнең үтәлеше турында Татарстан Республикасы Президентына мәгълүмат әзерләү бурычларын Аппаратның структур бүлекчәсенә яисә Аппаратның вазыйфаи затына йөкләү турында.

Әзерләнгән беркетмә (йөкләмәләр исемлеге) проектына тиешле өлкәдә Татарстан Республикасы Президентының эшчәнлеген тәэмин итүче Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе яисә Аппаратның структур бүлекчәсе яисә киңәшмәне (чараны) уздыру инициаторы булган орган җитәкчесе, Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы (беркетмә (йөкләмәләр исемлеге) проектында хокукый бәя бирелергә тиешле нигезләмәләр булганда), Аппарат Җитәкчесе тарафыннан виза куела һәм Татарстан Республикасы Президентына раслауга бирелә.

Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан расланганнан соң, беркетмә (йөкләмәләр исемлеге) Эшләр идарәсенең гомуми бүлегенә теркәү өчен тапшырыла.».

3. 4.3 пунктта:

а) беренче абзацта «беркетмә» сүзеннән соң «(йөкләмәләр исемлеге)» сүзләрен, «беркетмәнең» сүзеннән соң «(йөкләмәләр исемлегенең)» сүзләрен өстәргә;

б) икенче абзацта «беркетмә» сүзеннән соң «(йөкләмәләр исемлеге)» сүзләрен өстәргә.

4. 4.4 пунктта «беркетмәдә» сүзеннән соң «(йөкләмәләр исемлегендә)» сүзләрен өстәргә.

5. 4.5 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

6. 4.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Аппарат Җитәкчесендә уздырылган киңәшмә йомгаклары буенча беркетмә (Аппарат Җитәкчесенең йөкләмәләр исемлеге) төзелгән очракта, йөкләмәләрнең үтәлүен тикшереп тору беркетмәдә (йөкләмәләр исемлегендә) күрсәтелгән вазыйфаи зат яисә структур бүлекчә тарафыннан башкарыла.

Аппарат Җитәкчесенең телдән биргән йөкләмәләре йөкләмәләр исемлеге белән рәсмиләштерелә.».

7. 5.2.2 пунктчасында «беркетмәдә» сүзләреннән соң «(йөкләмәләр исемлегендә)» сүзләрен өстәргә.

8. 5.2.3 пунктчасында «беркетмәдә» сүзләреннән соң «(йөкләмәләр исемлегендә)» сүзләрен, «беркетмәнең» сүзеннән соң «(йөкләмәләр исемлегенең)» сүзләрен өстәргә.

9. 5.4.3 пунктчасында «беркетмәнең» сүзеннән соң «, йөкләмәләр исемлегенең» сүзләрен, «беркетмә» сүзеннән соң «, йөкләмәләр исемлеге» сүзләрен өстәргә.

10. 5.4.4 пунктчасында «беркетмә» сүзеннән соң «, йөкләмәләр исемлеге» сүзләрен өстәргә.

11. 5.4.5 пунктчасында «киңәшмә беркетмәләрендә» сүзләреннән соң «(йөкләмәләр исемлегендә)» сүзләрен өстәргә;

12. 21.11 пунктта:

а) икенче абзацтагы «беркетмәнең» сүзеннән соң «(йөкләмәләр исемлегенең)» сүзләрен өстәргә;

б) өченче абзацта «беркетмәнең» сүзеннән соң «(йөкләмәләр исемлегенең)» сүзләрен өстәргә;

в) дүртенче абзацта «беркетмә» сүзеннән соң «(йөкләмәләр исемлеге)» сүзләрен өстәргә;

г) бишенче абзацта «чара беркетмәсенең» сүзен «чара йомгаклары буенча әзерләнгән беркетмәнең (йөкләмәләр исемлегенең),» сүзләрен өстәргә.

---